**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 4 Әбсәләм ав. 31 январь 2022 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә вәкаләтләрен тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 14 һәм 15 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 16 маддәләре, 2019 елның 17 июлендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 8 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Усатвы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге

**К А Р А Р И Т Т Е:**

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен бирү:

- адресларны бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары атамаларын бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыру буенча;
- муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру турындагы документларны рәсмиләштерү буенча.

2. Вәкаләтләрне тапшыру турында "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән адресларны бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары атамаларын бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат

урнаштыру һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча килешү төзергә .

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының социаль мәсьәләләр буенча комиссиясенә йөкләргә.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева